| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>РУНГИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЫРЫҢГЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 20 » июнь 2018 ел № 2-51

ТР Буа муниципаль районы
Ырыңгы авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

02.03.2007 елгы 25-ФЗ номерлы «РФ муниципаль хезмәт турында», 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы «РФ җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнар, от 25.06.2013 елгы 50-ЗРТ номерлы "Муниципаль хезмәт турында" ТР Кодексы нигезендә, һәм муниципаль норматив хокук актын законга туры китерү максатында, ТР Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

I. 07.09.2016 елгы 1-16 номерлы (23.11.2016 елгы 1-22 номерлы, 25.08.2017 елгы 2-33 номерлы, 03.11.2017 елгы 1-38 номерлы, 05.04.2018 елгы 47 номерлы, 05.04.2018 елгы 48 номерлы, 23.05.2018 елгы 2-50 номерлы Карарлар редакциясендә) Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлеге Советы Карары белән расланган ТР Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1.1 Главу 6 бүлекне үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:**

«**6. Муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен квалификацион таләпләр.**

1. Муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен, түбәндәге квалификацион таләпләргә туры килү таләп ителә: һөнәри белем дәрәҗәсе, муниципаль хезмәт яки белгечлек буенча эш стажы, әзерлек юнәлеше, вазифаи йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләр, шулай ук эш бирүче вәкилнең карары булган очракта- белгечлек, әзерлек юнәлеше.

2. Вазифаи йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсе, муниципаль хезмәт яки белгечлек буенча эш стажы, әзерлек юнәлешенә карата квалификацион таләпләр, муниципаль хокук актлары тарафыннан әлеге бүлекнең 3 өлешендә күрсәтелгән муниципаль хезмәт вазифаи йөкләмәләрен үтәү өчен типологик квалификацион таләпләр нигезендә билгеләнә. Вазифаи йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләргә карата квалификацион таләпләр муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәт төре белән бәйле рәвештә аның вазифаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясе белән шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификацион таләпләр дә билгеләнә.

3. Муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен, түбәндәге типологик квалификацион таләпләр билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: вазифаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен - югары белем булуы; вазифаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен – югары яки урта һөнәри белем булуы;

2) муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажының ике елдан да ким булмавы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажының биш елдан да ким булмавы;

муниципаль хезмәтнең төп вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажының бер елдан да ким булмавы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажының ике елдан да ким булмавы;

муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажының бер елдан да ким булмавы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажының ике елдан да ким булмавы;

4. Муниципаль хезмәтнең өлкән һәм кече төркемнәре өчен вазифаларны алмаштыру өчен муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификацион таләпләр билгеләнми.

5. Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә, дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында һәм аңа тигезләшкән хәрби хезмәт вазифаларында һәм федераль дәүләт хезмәтенең башка төрләрендә эшләү стажы да исәпкә алына.

6. Муниципаль районның (шәһәр округының) җирле үзидарә администрациясе башлыгының контракт белән билгеләнгән вазифасына кандидатлыкка карата өстәмә таләп булып идарә эшчәнлеге тәҗрибәсенең биш елдан да ким булмавы тора. Әлеге өлештә идарә эшчәнлеге дип җитәкче, оешма, дәүләт органы, муниципаль орган җитәкчесе вазифаларында, шулай ук аларның структур бүленешләренең җитәкче вазифаларында эшләү дип аңлашыла. Җирле үзидарә администрациясе башлыгының контракт белән билгеләнгән вазифасына кандидатлыкка карата өстәмә таләпләр Буа муниципаль районы Уставы белән билгеләнә ала.

7. Белгеч яки магистр кызыл дипломлы затлар өчен диплом биргән көннән алып өч ел дәвамында муниципаль хезмәт стажына яки муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазифаларын алмаштыру өчен белгечлек буенча эш стажына квалификацион таләпләр билгеләнә - муниципаль хезмәт стажы ярты ел яки белгечлек буенча эш стажы бер ел булырга тиеш.

8. Әгәр җирле үзидарә администрациясе башлыгының вазифасына кеше контракт белән билгеләнсә, Уставом Буа муниципаль районы Уставы һәм ТР законы белән җирле үзидарә администрациясе башлыгы вазифасына кандидатлыкка карата өстәмә таләпләр билгеләнә.»;

**1.2 13 бүлектә:**

**13.2 пунктның 5 пункт астын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:**

«5) ежемесячная надбавка за классны чин өчен һәр айлык өстәмә»;

**13.3 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:**

«13.3 Муниципаль хокук актлары белән, РФ Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләрне үтәгән чракта, шулай ук түбәндәге өстәмә түләүләр каралырга мөмкин:

1) муниципаль хезмәткәрләргә нормага салынмаган эш көне шартларында эшләгән өчен һәр айлык компенсацион түләү;

2) төп хезмәт йөкләмәләренә хокук актларына һәм хокук актлары проектларына хокук экспертизасы үткәрү, хокук актлары проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларга юрист яки югары юридик белемле башкаручы буларак кул кую кергән муниципаль хезмәткәрләргә һәр йлык компенсацион түләү;

3) муниципаль хезмәткәрләрнең вазифа окладына профильле фән кандидаты, фән докторы гйльми дәрәҗәләре өчен һәр айлык өстәмә түләү;

4) муниципаль хезмәткәрләрнең вазифа окладына Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен һәр айлык өстәмә түләү;

2. 23.11.2016 елгы 1-22 номерлы “07.09.2016 елдагы 1-16 номерлы Ырыңгы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” Ырыңгы авыл җирлеге Советы Карарының 2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Әлеге Карар рәсми рәвештә бастырылган көннән алып үз көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча ТР хокукый мәгълүмат Рәсми порталының рәсми сайтында, шулай ук http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә ТР муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырылачак”.

II. Әлеге Карар рәсми рәвештә бастырылган көннән алып үз көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча ТР хокукый мәгълүмат Рәсми порталының рәсми сайтында, шулай ук http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә ТР муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырылачак.

III. Әлеге карарның үтәлүен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының
Ырыңгы авыл җирлеге Башлыгы Р.И. Гордеев